**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Урсай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Урсай авылы №39 11 октябрь 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советының 2014 елның 18.08. 104 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (19.11.2015 №18, 16.12.2016 №49, 23.04.2019 №137, 16.02.2020 №165, 15.03.2021 №24 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 апрелендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 16 июлендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Урсай авыл җирлеге советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советының 2014 елның 18.08. 104 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (19.11.2015 №18, 16.12.2016 №49, 23.04.2019 №137, 16.02.2020 №165, 15.03.2021 №24 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәнең 1 бүлегендә 6, 7 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Россия Федерациясе гражданлыгы йә чит ил гражданлыгы (подданствосы) Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы туктатылу, аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы;

7) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә чит ил территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булу;».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис _______________ З.Х. Рахимьянова

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКИ АЗНАКАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
УРСАЕВСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1602002416
КПП 164301001